КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 3 май г.Казань № 6-835

1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү уңаеннан:

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү, шул исәптән Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарын медицина белән һәм матди тәэмин итүне, аларның социаль-көнкүреш шартларын яхшырту һәм аларга өстәмә ярдәм күрсәтү чараларын эшләргә һәм үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе таләпләрен үтәп, 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгын бәйрәм итү кысаларында үткәрелә торган чараларда республика иҗтимагый оешмалары вәкилләренең катнашуын оештырырга;

Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе таләпләрен үтәп, Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар арасында 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгына багышланган тематик чаралар үткәрергә.

3. Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге – дәүләт учреждениесенә медицина күрсәткечләре булганда шифаханә-курорт дәвалануына юллама бирү өлешендә социаль хезмәт күрсәтүдән файдаланудан баш тартмаган 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышы инвалидларына һәм анда катнашучыларга шифаханә-курорт дәвалануын беренче чиратта бирү эшен оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын (хәрби хәрәкәтләрне, фронттагы һәм тылдагы батырлыкларны) яктырта торган онытылмас хатирәләр рубрикаларын урнаштыру, вакыйгаларда

катнашучыларның шәхси истәлекләрен бастырып чыгару эшен, шулай ук 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгына багышланган чараларны яктыртуны оештырырга.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына «Россия Федерациясе гражданнарына патриотик тәрбия бирү» дәүләт программасы кысаларында:

Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары арасында «Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерүгә багышланган иң яхшы музей (музей экспозициясе)» номинациясендә «Ватан геройлары» проекты кысаларында конкурс үткәрергә;

Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе таләпләрен үтәп, ветераннар оешмалары вәкилләренең, тыл хезмәтчәннәренең, локаль сугышларда катнашучыларның балалар йортларында тәрбияләнүчеләр, гомуми белем бирү оешмалары студентлары, һөнәри белем бирү оешмалары студентлары белән очрашуларын оештырырга;

Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе таләпләрен үтәп, гомуми белем бирү оешмалары укучыларының, һөнәри белем бирү оешмалары студентларының «Казан ярминкәсе» ачык акционерлык җәмгыяте базасында 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышы тарихына багышланган экспозициядә, «Россия – минем тарихым» мультимедиа тарихый паркында, «1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын яктырта торган Бөек Ватан сугышы музей-мемориалында булуын оештырырга;

«ЮНАРМИЯ» бөтенроссия хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге белән берлектә, яшь армия отрядларының республика чараларында катнашуына мониторинг үткәрергә.

6. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына волонтерлар оешмаларының һәм студентлар отрядларының истәлекле урыннарны, дан аллеяларын һәм зиратларда Бөек Ватан сугышы ветераннары җирләнгән урыннарны төзекләндерүдә катнашуын оештырырга.

7. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгын бәйрәм итү кысаларында Бөек Ватан сугышы ветераннарына мәдәният учреждениеләренә түләүсез йөрү хокукын бирү мөмкинлеген карарга.

8. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

ел ахырына кадәр «тыл хезмәтчәннәре» категориясе ветераннарына диспансеризация үткәрүне дәвам итеп, Бөек Ватан сугышы ветераннарына (Бөек Ватан сугышы инвалидларына һәм ветераннарына, «Блокадалы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән затларга, һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм анда катнашучыларның тол хатыннарына, фашизмның элеккеге тоткыннарына) диспансеризация оештырырга һәм үткәрергә;

дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә ветераннар өчен махсуслаштырылган палаталарның уңайлылыгын арттыру һәм аларны тиешенчә карап тоту чараларын үткәрергә, шулай ук алардан максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

бүлеп бирелгән финанслау күләмнәре кысаларында федераль һәм республика норматив документлары нигезендә Бөек Ватан сугышы инвалидларын һәм ветераннарын, шулай ук аларга тиңләштерелгән затларны бушлай рецептлар буенча дару препаратлары һәм медицина билгеләнешендәге әйберләр белән тәэмин итүне гамәлгә ашырырга.

9. Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

социаль яклау органнары белән берлектә, социаль хезмәт күрсәтүче стационар учреждениеләрдә Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарын котлауны оештыруны;

ветераннарның яшәү шартларын тикшерү, торакка капиталь ремонт ясау кирәклеген ачыклау чараларын үткәрүне, торак сатып алу өчен субсидия алган ветераннарның күченүен тикшерүдә тотуны тәэмин итүне;

Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән берлектә, 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү, шул исәптән сугыш ветераннарын медицина белән һәм матди тәэмин итүне, аларның социаль-көнкүреш шартларын яхшырту һәм аларга өстәмә ярдәм күрсәтү чараларын эшләүне һәм үткәрүне;

ветераннарны һәм тыл хезмәтчәннәрен җәлеп итеп һәм Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе таләпләрен үтәп, 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгына багышланган спорт һәм массакүләм иҗтимагый чаралар оештыруны;

1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын яктырта торган музей экспозицияләрен һәм күргәзмәләрен булдыруны яки яңартуны;

халыкны социаль яклау, сәламәтлек саклау, мәгариф органнары, иҗтимагый оешмалар һәм предприятиеләр вәкилләре белән берлектә, 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышы ветераннарының социаль паспортларын алып бару һәм үз вакытында актуальләштерү, ветераннарның сораулары буенча чараларны гамәлгә ашыру эшен дәвам итүне;

«ЮНАРМИЯ» бөтенроссия хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге белән берлектә, яшь армия отрядларының 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгына багышланган тантаналы чараларда, «Җиңү парады», «Хәтер вахтасы», «Үлемсез полк» акцияләрендә катнашуын оештыруны;

Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары территориясендә урнашкан интернат йортларда яшәүче 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм анда катнашучыларның торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүне;

«Җиңү волонтерлары» төбәк хәрәкәте җирле бүлекләренең социаль әһәмиятле акцияләрен тормышка ашыруга ярдәм күрсәтергә, 2021 елга «Җиңү волонтерлары» проекты чаралары планын эшләүне һәм раслауны.

10. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан предприятиеләргә һәм оешмаларга, Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча

идарәсе таләпләрен үтәп, 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган тантаналы чаралар эшләүне һәм үткәрүне тәкъдим итәргә.

11. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин